ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (II өлеш); 2011, № 10 (II өлеш), 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Дәүләт мөлкәте өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибе, шулай ук аренда түләве буенча ташламалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 77-ТРЗ